**СОВЕТ НАРМОНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 с. Нармонка,
ул. Молодежная , д.12 а
тел: 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
422630 Нармонка авылы,
Яшьләр урамы, 12 а нчы йорт,
тел: 4-62-24

---

**2025 елның 5 декабре** **30 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 12 декабрендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Терлекләр белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 498-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында" 2018 елның 12 декабрендәге 127 номерлы карарына X бүлек өстәргә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Нармонка**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Ф. Мөбәрәкшин**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районының**
**2025 елның 5 декабрендәге 30 номерлы**
**Нармонка авыл җирлеге Советы карарына**
**1нче кушымта**

## X нчы бүлек. Йорт хайваннарын һәм кошларын тоту

175. Йорт хайваннарын һәм кошларны тоту өченче затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозмаска тиеш. Йорт хайваннары һәм кошлар китергән зыян өчен аларның хуҗалары РФ законнары белән билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

176. Йорт хайваннары хуҗалары үз йорт хайваннарының экскрементларын үзләре җыялар һәм утильләштерәләр.

177. Җирлектә яшәүчеләр тарафыннан авыл хуҗалыгы хайваннарын (сыерларны, сарыкларны, кәҗәләрне, дуңгызларны һәм башкаларны) һәм кошларны тоту шәхси торак йортлар территорияләрендә һәм йорт яны кишәрлекләрендә рөхсәт ителә.

178. Барлык продуктив хайваннар (эре мөгезле терлек, кәҗә, сарык, дуңгыз, ат) биркалау юлы белән мәҗбүри теркәлергә һәм гражданнарның - хайван хуҗаларының яшәү урыны буенча ветеринария учреждениеләрендә ел саен яңадан теркәлергә тиеш.

179. Йорт хайваннарын җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган көтү урыннарында хуҗасы күзәтүе астында яисә аның кушуы буенча башка зат көтүе рөхсәт ителә.

180. Йорт хайваннарын 7.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр йөртергә рөхсәт ителә. Башка вакытта урамда йөргәндә хуҗалар урамнарда һәм торак йортларның ишегалларында тынлыкны тәэмин итү өчен чаралар күрергә тиеш.

181. Этләрне торак һәм изоляцияләнгән биналардан гомуми ишегалларына һәм урамга бары тик кыска тезгендә һәм борынчыкта гына чыгарырга мөмкин, өч айга кадәрге көчекләрдән тыш.

182. Хуҗалар йорт хайваннары һәм кошлар белән ишегалларын, тротуарларны, урамнарны, паркларны, газоннарны, балалар мәйданчыкларын, скверларны, мәйданнарны, шулай ук торак йортларның подъездларын пычратмаска тиеш. Этләрне, мәчеләрне һәм башка вак хайваннарны йөрткәндә, йорт хайваннарының чүп контейнерларына чыгарылырга тиешле табигый тизәкләрен тулысынча җыештыруны тәэмин итә торган кирәк-яраклар хуҗаның үзе белән булырга тиеш.

183. Этне тезгеннән йөртү урыннарында гына ычкындырырга мөмкин. Махсус билгеләнгән мәйданчыклар булмаганда, җирле үзидарә органының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган бушлыкларда, калкулыкларда һәм башка урыннарда йөрергә рөхсәт ителә.

184. Этләрне өйрәтү бары тик яхшы әйләндереп алынган мәйданчыкларда яисә җирлек территориясеннән читтә генә башкарыла ала.

185. Йорт хайваннарын тәүлекнең якты вакытында гына юлдан куып барырга кирәк, шул ук вакытта аларны юлның уң ягына мөмкин кадәр якынрак җибәрергә кирәк. Йорт хайваннарын, грунт юллардан һәм сукмаклардан куып бару мөмкинлеге булганда, асфальт түшәлгән юлда йөртү тыела.

186. Йорт хайваннарын урамда калдырганда, терлек асраучылар яшеллекләрне бозудан килгән зыянны һәм терлекләрне утау чыгымнарын каплыйлар.

187. Йорт кәҗәләре бары тик йорт яны территориясендәге утарларда яисә көтүлектә хуҗалары күзәтүе астында тотылырга тиеш.

188. Рөхсәт ителми:

1) хайваннарны балалар мәйданчыкларына, мәктәпләр, балалар бакчалары территорияләренә, ашханәләргә, поликлиникаларга, азык-төлек кибетләренә кертергә;

2) йорт хайваннарын пляжларда йөртү һәм аларны сулыкларда коендыру;

3) хайваннарны тыю язуы булганда учреждениеләргә кертергә;

4) торак пунктлар территорияләрендә хайваннарны һәм кошларны озатучысыз чыгарырга;

5) исерек хәлдәге затларга, шулай ук ундүрт яшькә җитмәгән затларга хайваннар йөртергә;

6) йорт хайваннарын һәм кошларын балконнарда, лоджияләрдә, торак йортларның гомуми файдалану урыннарында (чиктәш фатирлар коридорларында, баскыч шакмакларында, чормаларда, подвалларда һәм башка ярдәмче биналарда)даими тоту;

7) җирлекләр территориясендә йорт хайваннарының, махсуслаштырылган чаралар (күргәзмәләр һ.б.) уздыру урыннарыннан тыш, моның өчен бүлеп бирелгән урыннардан читтә булуы.

189. Йорт хайваннары һәм кошлары ияләренә:

1) терлек авыруларын кисәтүне һәм терлекчелек продуктларының ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыгын  тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашырырга, әйләнә-тирә мохитне терлекчелек калдыклары белән пычратуга юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чаралары үткәрергә;

2) хайваннарның тору урынын даими контрольдә тотарга;

3) хайваннар авырганда һәм алар үлгән очракта, шулай ук аларның үз-үзләрен гадәти булмаган тотышлары булганда ветеринария учреждениеләре белгечләренә кичекмәстән хәбәр итәргә. Алар килгәнче авыру билгеләре булган хайваннарны изоляцияләргә;

4) терлекләрне карау, диагностик тикшеренүләр, саклагыч прививкалар һәм дәвалау-профилактик эшкәртүләр өчен ветеринария белгечләре таләбе буенча бирергә.

190. Үлгән терлекне махсус билгеләнгән урында махсус оешма җирли.

191. Үз территориясендә сакчы этләре булган оешмаларга:

1) этләрне гомуми нигезләрдә теркәргә;

2) этләрне нык бәйләп асрау;

3) килүчеләрнең хайваннардан файдалану мөмкинлеген булдырмаска;

4) этләрне эш туктатылганнан соң яхшы әйләндереп алынган территориядә яисә территориягә кергәндә кисәтү язуы булганда, гомуми файдалану территориясеннән аерылган территориядә генә бәйләвечтән җибәрергә.

192. Җәмәгать урыннарында озатып йөрүче затлардан башка булган күзәтүчесез хайваннар тотылырга тиеш.

193. Күзәтүчесез калган хайваннарны аулауны мондый хайваннарны тапкан махсуслаштырылган предприятие яисә башка зат җирле үзидарә органнары белән төзелгән килешү буенча башкарырга мөмкин.

194. Хуҗасыз калган хайваннарны аулау чараларын гамәлгә ашыру хайваннарга карата гуманлы мөнәсәбәт һәм иҗтимагый әхлак нормаларын үтәү принципларына нигезләнә.

195. Рөхсәт ителми:

1) хайваннарны судның тиешле карарыннан башка фатирлардан һәм хосусый йорт биләмәләре территориясеннән алырга;

2) кибетләр, даруханәләр, коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре янында этләрне бәйдән ычкындырырга.;

3) ветеринария органнары тәкъдименнән башка хайваннарны тоту тозакларын һәм башка чараларны файдаланырга.